**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИЖЕВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

29.06.2026 № 11

Менделеевск муниципаль районы
Ижевка авыл җирлеге оешмалары
абонентларыннан су агызу системасына
керә торган агып төшүче суларның составына
рөхсәт ителә торган нормативлар турында

"Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү турында" 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, "Әйләнә-тирә мохитне саклау турында", "Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү турында" 2022 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон; Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Агып төшүче суларның составын һәм үзлекләрен тикшереп торуны гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм аларның үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2020 елның 22 маендагы 728 номерлы карары нигезендә, әйләнә-тирә мохиткә пычраткыч матдәләрнең тискәре йогынтысын, су объектларын пычратуны кисәтү максатларында, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлеге оешмалары абонентларыннан су агызу системасына керә торган агып төшүче суларның составына рөхсәт ителә торган нормативларны кушымта нигезендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 28 октябрендәге 16 нчы номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru / һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында https://mendeleevsk.tatarstan.ru «Ижевка авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Ижевка авыл җирлеге башлыгы Р.Т.Мәсәгутова

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлеге Башкарма комитетының 2026 елның 29 июнь 11 номерлы карарына кушымта

Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлеге оешмалары абонентларыннан су агызу системасына керә торган агып төшүче суларның составына рөхсәт ителә торган нормативлар

| Пычраткыч матдәләрнең аталышы | Пычраткыч матдәләрнең рөхсәт ителгән концентрацияләре, мг/дм3 |
|---|---|
| 1 | 2 |
| рН | 6,5 –8,5 |
| Үлчәүле матдәләр | 300 |
| Гомуми азот | 50 |
| Хлоридлар | 1000 |
| Нефть продуктлары | 0,69 |
| Сульфатлар | 592,4 |
| Кислородны тулысынча биохимик куллану | 300 (500) |
| Гомуми тимер | 5 |
| Фосфор | 13,74 |
| Синтетик өске-актив матдәләр. | 7,41 |
| Алюминий | 0,76 |
| Марганец | 0,19 |
| Бакыр | 0,0095 |
| Фенол | 0,0028 |